**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЧЕРЕМШАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396) 2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 ноябрь 2025 ел** **№ 18**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 20 декабрендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 20 декабрендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегендә 2.5.1 пунктының 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм әгәр федераль закон нигезендә мондый шәхси мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Г.Долгополов